ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» декабря 2023 ел № 407

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль мәгариф оешмаларында гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның кайнар туклануын оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнар билгеләү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 30.10.2023 елның 334 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Мәктәп яшендәге инвалидларны (инвалид балаларны) икетапкыр кайнар азык белән тәэмин итү турында» 09.12.2023 елның АБ-4617/07 номерлы хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында муниципаль мәгариф оешмаларында гомуми белем бирү программалары буенча укучыларны кайнар тукландыруны оештыруга һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнар билгеләү турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 30.10.2023 елның 334 номерлы карарының 1 пунктындагы 1.7 пунктчасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм инвалидлар (инвалид балалар) өчен мәктәптә (шул исәптән, укыту өйдә оештырылган) ике тапкыр кайнар туклану оештырырга, кайда:
- Шәһәр мәктәпләре өчен көнгә 75 сум 80 тиен (9 сум 20 тиен күләмендә субсидия күләмен кертеп);
- Авыл мәктәпләре өчен көнгә 58 сум 10 тиен 9 сум 20 тиен күләмендә субсидия күләмен кертеп)».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырг(https://agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Г.Ф. Җәметовага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**